**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Илбәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Илбәк авылы | № 9 | «22» сентябрь 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авылы җирлеге Советының 2016 елның 23 декабрендәге 43 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең генераль планы турында» карарын гамәлдән чыгару хакында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авылы җирлеге Советының 2016 елның 23 декабрендәге 43 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең генераль планы турында» карарын исәпкә алып һәм норматив хокукый актларның кабатлануын булдырмау максатыннан,

Илбәк авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авылы җирлеге Советының 2016 елның 23 декабрендәге 43 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең генераль планы турында» карарын гамәлдән чыгарырга.

**2.** Әлеге карар 2020 елның 24 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис — Л.Р.Әсәдуллина